БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 06 2020 ел № 202

"Балтач муниципаль районында кече бизнес (эшкуарлык) өлкәсендә яшьләр арасында бизнес-проектлар конкурсын раслау турында" 2020 елның 14 маендагы 175 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Балтач муниципаль районында кече бизнес (эшкуарлык) өлкәсендә яшьләр арасында бизнес-проектлар конкурсы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законны һәм "2019-2024 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү" муниципаль программасын раслау турында" 2020 елның 17 апрелендәге 151 номерлы Балтач район башкарма комитеты карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. "Балтач муниципаль районында кече бизнес (эшкуарлык) өлкәсендә яшьләр арасында бизнес-проектлар конкурсын раслау турында" 2020 елның 14 маендагы 175 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Балтач муниципаль районында кече бизнес (эшкуарлык) өлкәсендә яшьләр арасында бизнес-проектлар конкурсы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә.

2. 4 өлешнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.2. Конкурска гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач ш. т. п., Ленин урамы, 42 нче йорт.

Конкурс гаризаларын тапшыру вакыты - 2020 елның 20 маеннан 2020 елның 15 июненә кадәр.

Гаризалар һәм бизнес-проектларны карау вакыты - 2020 елның 15 июленнән 20 июленә кадәр.

Яклау һәм эксперт бәяләве - 2020 елның 23 июленнән 25 июленә кадәр.

Уку этабы - 2020 елның 29 июленнән 30 июленә кадәр.

Конкурска йомгак ясау - 2020 елның 30 июлендә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми http://baltasi.tatarstan.ru сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерегә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе

А.Ф. Хәйретдинов